

Мордовия Республикасы Госсоб-рание депутаты, «Бердәм Россия» фракциясе әгъзасы Ринат Рафик улы Раимов 4нче Республика клиник хастаханәсенә ярдәм кvрсәтте. «Кызыл зона»да дежур торган табибларга парламентарий кулерлар очен эчәргә яраклы су запасын һәм бер тапкыр кулланыла торган савыт-саба китергән. «Хәзер медиклардан бик зур жаваплылык сорала, һәм без аларга момкин булган кадәр ярдәм кvрсәтергә тиеш. Хастаханәнен чиста эчә торган су запасы тулыланды, бу берничә атнага житәргә тиеш», - дип билгеләп vтә Ринат Рафик улы.      Медучреждениенен баш шәфкать туташы Галина ханым Назимова сvзләренә караганда, бvген медицина персоналына мондый игътибар бик моһим һәм кирәк. Ул хастаханә житәкчелеге исеменнән Мордовия Госсобраниесы депутатына vз вакытында ярдәм итvләре һәм битараф булмаулары очен рәхмәт белдергән.
Пандемия башланганнан бирле, Ринат Рафик улы Раимов, яна коронавирус йогышы белән корәшvче Мордовия медикларына ярдәм кvрсәтv эшенә кушылды.
Мордовия Республикасы Дәvләт жыелышы Рәисе Владимир Чибиркин адресына Дубенка районы больницасы житәкчелегеннән һәм медицина персоналыннан Рәхмәт килгән, анда болай диелә: «Ринат Рафик улы авыруга каршы торуда, беренче кирәкле товарлар: саклагыч чаралар, антисептиклар, бер тапкыр кулланыла торган перчаткалар, эчә торган су һәм азык-толек жыелмалары биреп, ярдәм кулын сузды. Безнен очен, сәламәтлек саклау хезмәткәрләре очен, кvр-сәтелгән ярдәм кирәк; Дубенка районы халкынын сәламәтлеген саклау буенча Р.Р.Раимов кондәлек эштә булыша. Зур рәхмәт!».

**Н.ХӘЛИЛ**